БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» 02 2024 ел № 78

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының « Җир эшләрен башкару өчен ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 20 августындагы 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2023 елның 21 декабрендәге 02-07-2023/Прдп636 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Җир эшләрен башкару өчен ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 20 августындагы 264 номерлы карарына, карарның кереш өлешендәге (преамбулада) « Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарына таянып» дигән сүзләрне төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 264 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.2. пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов